***Иҗтимагый һәм дини оешмалар белән үзара бәйләнешләр***

Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара татулыкны саклау Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Татарстан башкаласында 115 тән артык милләт вәкилләре яши, 36 милли-мәдәни автономия, 181 дини оешма эшләп килә, 61 сәяси партия, 100 дән артык иҗтимагый-сәяси хәрәкәт һәм оешма теркәлгән.

Казан өчен 2017 ел милләтара һәм динара өлкәдә әһәмиятле чараларга бай булды. Бу – Татарстан мөселманнарының VII съезды; Татарстан халыкларының III съезды, Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды, социаль юнәлештәге коммерцияле булмаган оешмаларның IV форумы кысаларында милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне җайлаштыруның актуаль мәсьәләләре буенча дискуссия, Европа Советының Милли азчылыкны саклау буенча кыса комиссиясе кысаларында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл, Татарстан Республикасы православие җәмәгатьчелегенең III форумы.

**Дини оешмалар белән эшләү турында**

Хәзерге вакытта Казанда 118 гыйбадәт объектлары эшләп килә, шулардан: 60 мәчет (2016 елда – 59), 43 православие чиркәве, 12 башка христиан юнәлешендәге чиркәү, 1 синагога, Бахаи һәм Кришна гыйбадәтханәләре.

Татарстан башкаласында барлыгы 181 дини оешма эшләп килә: 88 – ислам, 49 – православие, 2 – иске динчелек чиркәве, 1 – католик, 1 әрмән апостол, 35 - протестант, 2 – иудейлык, 1 – бахаи, 1 – кришнаитлар һәм 1 – буддистлар.

2017 елның 17 апрелендә Казан шәһәрендә Татарстан мөселманнарының VII съезды узды, анда бар республикадан 1200 дән артык имам, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары катнашты. Съездда Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе булып Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстан Республикасының баш казые булып Җәлил хәзрәт Фазлыев яңадан сайланды.

2017 елның 19 октябрендә Казан шәһәре Башкарма комитетында Казан шәһәрендә 24 ноябрьдә узган Татарстан Республикасының православие җәмәгатьчелегенең III форумы алдыннан очрашу үткәрелде. Очрашуда катнашучылар планнар, булган проблемалар, уртак бурычлар, шулай ук ниятләгән чаралар хакында фикер алыштылар.

2017 ел православие һәм мөселман руханиларының үзара бәйләнешләре мәсьәләсендә дә үрнәк булды. Спорт, интеллектуаль һәм хәйриячелек

чаралары милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайлаштыруга юнәлтелде. 2017 елның ноябрь-декабрь айларында Казан шәһәренең православие чиркәүләре һәм мәчетләре 2014-2018 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программа кысаларында уздырылган Православие һәм мөселман яшьләре спартакиадасында катнаштылар. Руханилыклар вәкилләре конфессияләр арасында тынычлык һәм килешү үрнәге булуларын тагын бер кат күрсәттеләр.

«Казан шәһәренең иң яхшы гыйбадәт объектлары» конкурсында 28 православие чиркәве һәм 33 мәчет катнашты. 2017 елда Изге Рух иңү чиркәве һәм «Әл-Мәрҗани» мәчете җиңү яулады.

Казанда эшләп килүче бар мәчетләр дә ислам динендәге ике зур бәйрәм (Ураза гаете һәм Корбан гаете) вакытында дин тотучы 50 меңнән артык шәһәрлене һәм башкалабыз кунакларын кабул иттеләр. Өченче ел инде Корбан гаетендә биокалдыкларны заводта эшкәртү өчен Алабуга шәһәренә вакытында чыгару оештырыла. 15 июньдә Казанның теннис академиясендә V Республика ифтары оештырылды, анда 10 меңнән артык кеше катнашты. Гаисә Пәйгамбәрне чукындыру көнендә – 2017 елның 19 гыйнварында Казан епархиясенең бар чиркәүләрендә бәйрәм гыйбадәтләре узды. Чукыну йоласын үтәргә теләүче казанлылар өчен шәһәрдә 5 купель әзерләнгән иде. Йоланы үткәрү урыннарында кирәкле шартлар тудырылды, анда 7 мең тирәсе кеше катнашты.

Елына ике тапкыр Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясенә иң хөрмәтләнүче иконаларның берсе – Казан Изге Ана иконасы хөрмәтенә тәре йөрешен оештыру һәм үткәрүгә ярдәм күрсәтелә: 21 июльдә – иконаны табу хөрмәтенә һәм 4 ноябрьдә – иконаның данын күтәрү хөрмәтенә. Әлеге йөрешләрдә 11 меңнән артык кеше катнашты. Шулай ук 2017 елда икона табылган урында Казан Изге Ана иконасы чиркәвен торгызу буенча актив эш дәвам итте. Ел ахырына чиркәүнең биеклеге 39 метрга җитте.

**Милли-мәдәни автономияләр белән хезмәттәшлек**

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә 36 милли-мәдәни автономия эшләп килә.

Шәһәрдә балаларга мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә туган телдә белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар тудырылган. «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге эшләп килә. 2017/2018 уку елында Күпмилләтле якшәмбе мәктәбендә 22 бүлекчәдә 417 укучы укый (2016/2017 елда – 21 бүлекчәдә 363 укучы).

Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендә Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятен, традицияләрен һәм йолаларын өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Укучылар «Татар кызы», «Татар егете», «Добрый молодец», «Красна девица» шәһәр конкурсларында; М.Җәлилнең тууына 111 ел тулуга, Г.Тукайның тууына 131 ел тулуга, Рус теле көненә һәм А.С.Пушкинның тууына 218 ел тулуга багышланган чаралар комплексында; Кирилл-Мефодий укуларында, «Казан-йорт», «Ягымлы яз» фестивальләрендә актив катнаштылар; республика мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре һәм башкалар белән очрашулар үткәрелде. Татарстан халыклары дуслыгы йорты базасында Казан шәһәрендәге мәгариф учреждениеләренең 7 нче сыйныф укучылары өчен дуслык һәм бердәмлек дәресләре оештырыла. Һәр дәрестә 250 ләп укучы катнаша.
2017 елның ноябрендә – Казан шәһәре экскурсоводлары өчен укыту семинары, декабрендә документларны Татарстан Республикасының дәүләт телләренә тәрҗемә итүче һәм документларга лингвистик экспертиза ясаучы белгечләр өчен курслар үткәрелде.
Казан шәһәре Башкарма комитеты «Нардуган» керәшен халык бәйрәме, «Масленица» рус халык бәйрәме, төрки халыкларның «Нәүрүз» бәйрәме, «Сабантуй» татар милли бәйрәме, «Кузьминки» бөтенроссия фольклор-этнографик фестивале кебек традицион рәвештә ел саен уздырыла торган халык бәйрәмнәре һәм фестивальләрен һәм башка күп кенә чараларны оештыруда һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтте.
2017 елның 4 декабрендә С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында Казан шәһәре Башкарма комитеты һәм Татарстан халыклары ассамблеясы тарафыннан «Күпмилләтле Казан музыкасы» I фестивале оештырылды. Татарстан халыклары ассамблеясы һәм «Ялкын» журналы редакциясе белән берлектә ай саен «Ачык сандык» рубрикасы чыга һәм ел саен «Күпмилләтле Казан» журналы бастырыла. Һәр укучы Казан шәһәрендә яшәүче төрле халыкларның менталитеты, мәдәнияте, традицияләре, йолалары, аш-сулары, милли киемнәре, милли сәнгате һәм бәйрәмнәре, шулай ук телләре белән таныша ала. Милләтара һәм конфессияара низагларны кисәтү мәсьәләләре Татарстан халыклары ассамблеясы белән берлектә квартал саен түгәрәк өстәлләр барышында һәм хокук саклау органнары вәкилләре һәм Татарстан халыклары ассамблеясының милли иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләре катнашында Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә чит ил гражданнары тарафыннан кылына торган

хокук бозуларны профилактикалау буенча эш төркеме утырышларында карап тикшерелә.

**Иҗтимагый-сәяси характердагы ачык чаралар турында** Шәһәр территориясендә сәяси, икътисади һәм социаль хәлләрне анализлауга юнәлтелгән, сәяси партияләр, иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара бәйләнешләр буенча алып барыла торган эш Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегендә аерым урынны били. 2017 ел азагына Казан шәһәрендә 61 сәяси партия теркәлде. 2017 елда Казанда 276 төрле ачык чара үткәрелде. Аларда 28 меңнән артык кеше катнашты (2016 елда – 1586 чара, 56 мең кеше). Шулардан сәяси таләпләр булган 59 чара, социаль мәсьәләләр буенча – 25, агитация буенча – 13,
дини темаларга 179 чара үткәрелде. Җәмәгатьчелек арасында түбәндәге темалар киң яңгыраш тапты: республика гражданнарының социаль-икътисади хокукларын яклау, өлешләп төзүдә алданган кешеләр һәм ипотекада катнашучылар проблемасы, халыкның төрле социаль проблемалары, шулай ук яңа мәс
ьәләләр – банк кризисы, чүп яндыру заводы төзелеше, Октябрь революциясе юбилее, 2018 елда узачак Россия Федерациясе Президентын сайлауга
кандидатларның сайлау программасы һәм алар белән очрашулар турында мәгълүмат бирү.

**2018 елга бурычлар**

- Казан шәһәрендә милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм күрсәтү өчен уңай мохит булдыру; - Казан шәһәрендә 2014-2018 елларга гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаны үтәү; - Казан шәһәрендә милләтара һәм конфессияара аңлашып һәм килешеп яшәргә ярдәм итүче социаль әһәмияткә ия программаларны тормышка ашыруда дини һәм милли-мәдәни оешмаларга булышлык күрсәтү.